ГЛАВА
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

____25.03.2021____ Балык Бистәсе штп. №_87пг__

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 31маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 37 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турында“ 2006 елның 23 октябрендәге ПУ-431 номерлы Указын исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына эшне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге белән берлектә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга киңәш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрларын алып бару мәсьәләләре буенча методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә һәм "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында аларны алып баруны яраклаштыруны тәэмин итүне киңәш итәргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын алып бару тәртибе турында " 2016 елның 21 мартындагы 38пг номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2021 елның 25 мартында
87 пг номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрларын һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын алып бару тәртибен һәм эчтәлеген тәгаенли.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре реестрлары (алга таба – муниципаль хезмәт) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) шәхси эшләрендәге мәгълүматлар нигезендә төзелә.

3. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре Реестрын (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр реестры) төзи, ул җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр турында мәгълүматларның җыелма исемлегеннән гыйбарәт.

4. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрларына һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрына кертелгән мәгълүматлар, федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда, дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга керә, ә кайбер очракларда – конфиденциаль характердагы мәгълүматларга һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә якланырга (сакланырга) тиеш.

5. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестры "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының Бердәм мәгълүмат системасы" дәүләт Мәгълүмат системасында (алга таба –

Мәгълүмат системасы) алардагы мәгълүматка рөхсәтсез керү, юк итү, модификацияләү, блокадалау, күчермәләү, бирү, тарату, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән саклауны тәэмин итү белән алып барыла.

## II. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрын алып бару

6. Җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестры Мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре (алга таба – кадрлар хезмәте) буенча орган бүлекчәсе тарафыннан алып барыла.

7. Муниципаль хезмәткәрләр Реестрын төзү һәм алып бару Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан җирле үзидарә органнарында тәкъдим ителгән муниципаль хезмәткәрләр реестрлары нигезендә Мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла.

8. Җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестры һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестры рәвешләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты (алга таба – Департамент) тарафыннан расланган дәүләт органында дәүләт хезмәткәрләре реестры һәм Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләре Реестры рәвешләренә туры килә һәм Мәгълүмат системасында урнаштырыла.

9. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрлары һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестры түбәндәгеләр турындагы мәгълүматларны үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең персональ мәгълүматлары;

муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт уза торган җирле үзидарә органы аталышы;

әлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәсенең аталышы;

Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасының аталышы;

муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттә кадрлар резервына кертү (кадрлар резервына кертү датасы, вазыйфа аталышы, кадрлар резервына кертү нигезе, кадрлар резервыннан төшереп калдыру өчен нигез).

10. Муниципаль хезмәткәрнең шәхси мәгълүматлары түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының (булганда) исеме турында;

туу датасы турында;

һөнәри белем турында (белем бирү оешмасының аталышы, диплом номеры һәм датасы, белгечлек һәм квалификация);

хәрби хезмәт узу турында;

яңадан һөнәри әзерлек узу турында (белем бирү оешмасының аталышы, укуның тәмамлану датасы, программаның аталышы, йомгаклау документының төре һәм номеры);

квалификацияне күтәрү турында (белем бирү оешмасының аталышы, укуның

тәмамлану датасы, программаның аталышы, йомгаклау документының төре һәм номеры);

гыйльми дәрәҗә турында (гыйльми дәрәҗәнең аталышы, бирелү датасы);

гыйльми исем турында (гыйльми исемнең аталышы, бирелү датасы);

еллар, айлар, көннәр белән исәпләнгән гомуми хезмәт стажы турында;

муниципаль хезмәтнең елларда, айларда, көннәрдә исәпләнгән стажы турында;

аттестация узу турында (аттестациянең үткәрелү датасы, аттестация комиссиясе карары);

класс чины турында (класс чины, аны бирү турында актның датасы һәм номеры);

дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр турында (бүләк төре, бүләкләү датасы);

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс узу турында (әгәр граждан конкурс нәтиҗәләре буенча вазыйфасына билгеләнсә);

хезмәт шартнамәсе турында (контракт – Башкарма комитет җитәкчесе өчен) (хезмәт шартнамәсе төзүнең төре, датасы (Башкарма комитет җитәкчесе өчен – контракт), аның гамәлдә булу вакыты, аңа үзгәрешләр кертү датасы).

Муниципаль хезмәткәрләрнең әлеге персональ мәгълүматлары исемлеге тулы исемлек булып тора һәм бары тик җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларына һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрына карата гына кулланыла.

11. Муниципаль хезмәткә керүче граждannar турында мәгълүматлар җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәннән соң ике эш көне эчендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең (муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның) билгеләнү турындагы актлары нигезендә муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелә.

12. Муниципаль хезмәткәрне шул ук җирле үзидарә органында башка вазыйфага билгеләгәндә аны муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләү турындагы мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрләр реестрына җирле үзидарә органы җитәкчесе (муниципаль вазыйфаны биләүче зат) тарафыннан билгеләнгән көннән алып ике эш көне эчендә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнү турындагы акт нигезендә кертелә.

13. Муниципаль хезмәткәр турында мәгълүматларны җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрыннан төшереп калдыру өчен нигез булып аның эштән азат ителүе, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт булмаган вазыйфага билгеләнүе, үлеме (һәлак булуы), шулай ук затны хәбәрсез юк булган дип тану яисә аны закон көченә кергән суд карары белән үлгән дип тану тора.

Җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан муниципаль хезмәткәр турындагы мәгълүматларны төшереп калдыру өчен аны шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасына башка җирле үзидарә органында билгеләп кую нигез булып тора.

Күрсәтелгән нигезләр буенча муниципаль хезмәткәр турында мәгълүматлар эштән азат ителү, башка җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт

булмаган вазыйфага билгеләнү, үлгән (һәлак булган) көннең иртәгесе көнендә яисә тиешле суд карары закон көченә кергән көнне җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

14. Җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрында тиешле үзгәрешләр турындагы мәгълүматлар Мәгълүмат системасына кертелә һәм биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә җибәрелә.

Җирле үзидарә органындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан биш эш көне эчендә муниципаль хезмәткәрләр Реестрына үзгәрешләр кертү гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәткәрләр Реестрында тиешле үзгәрешләр турындагы мәгълүматлар биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан Департаментка юллана.

15. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт узган һәм җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарылган муниципаль хезмәткәрләр турындагы мәгълүматлар кануннар нигезендә архивка тапшырыла.

16. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрын алып бару белән бәйле бәхәсләр закон нигезендә хезмәт бәхәсләре буенча комиссияләр һәм суд тарафыннан карала.

## III. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып баруны контрольдә тоту

17. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең реестрын алып баруны җирле үзидарә органы җитәкчесе (муниципаль вазыйфаны биләүче зат) контрольдә тота.

Контроль шәхси эшләрнең һәм аларның торышын (халәтен) тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын үз эченә алган мәгълүматларны җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрындагы мәгълүматлар белән чагыштыру рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматларны чагыштыру факты тиешле актта чагылыш таба.

18. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм муниципаль хезмәткәрләр Реестрын төзү (булдыру) һәм алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән муниципаль хезмәткәрләр конфиденциаль характердагы мәгълүматларны һәм дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны тараткан өчен закон нигезендә җаваплы була.

## IV. Җирле үзидарә органнарындагы муниципаль хезмәткәрләр реестрларыннан, муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан мәгълүматлар бирү (тәкъдим итү) һәм реестрларны саклау

19. Муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан мәгълүматлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә кадрлар хезмәте тарафыннан бирелә.

20. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрлары, аларга кертелгән үзгәрешләр, алардагы мәгълүматка рөхсәтсез керүдән, юкка чыгарудан, модификацияләүдән, блокадалаудан, күчермәләүдән, бирүдән, таратудан, шулай ук башка законсыз гамәлләрдән яклауны (саклауны) тәэмин итеп, Мәгълүмати системада саклана.